МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.11.2022 Казан ш № 1027

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 4 октябрендәге 568 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 4 октябрендәге 568 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.12.2018 ел, №1145 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «инвалидлар белән эшләү бүлеге» сүзләрен «яшәеш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү тәртибендә:

2.1 пунктының икенче-дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза гражданинның яки аның законлы вәкиленең яисә гражданин тарафыннан вәкаләт бирелгән затның шәхси мөрәҗәгате вакытында яшәү урыны буенча социаль яклау территориаль органына тапшырылырга мөмкин, яисә кәгазьдә почта элемтәсе оешмасы аша яисә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет (алга таба – Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) аша җибәрелә.

Гариза биргәндә гражданин шәхесен раслаучы документны күрсәтә. Гариза гражданин тарафыннан вәкаләт бирелгән зат яисә законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта, вәкилнең шәхесен раслаучы документ һәм гражданинның мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслаучы документ күрсәтелә.

Гаризаны почта элемтәсе оешмасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризага гражданин тарафыннан вәкаләт бирелгән затның яисә гражданинның законлы вәкиленең гражданин мәнфәгатьләрендә эш итү хокукларын раслый торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре теркәлә.

3.2 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә);

3.3 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләпләре 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә);

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү актының икенче нөсхәсе, Федераль архив агентлыгының «Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган, аларны саклау срокларын күрсәтеп, типик идарә архив документлары исемлеген раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 236 номерлы боерыгы белән расланган, Аларны саклау срокларын күрсәтеп, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган типлаштырылган идарә архив документлары исемлегенең 152 пункты нигезендә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон һәм архив законнары нигезләмәләре нигезендә гариза белән социаль яклау территориаль органында тикшерү актларын бирүне исәпкә алу папкасында биш ел дәвамында саклана.»;

Күрсәтелгән Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Министр Э.Ә. Зарипова

Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү тәртибенә
1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 » 11.2022 № 1027 боерыгы редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының территориаль
органына

Инвалид балага сатып алынган товарны тикшерү актын бирү турында гариза*

______________________________________________________________
(ана (гаилә) капиталы дәүләт сертификаты хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________________________
(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының законлы вәкиле (булган очракта) фамилиясе, исеме, атасының исеме)

1. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ ____________________
__________________________________________-__________________________
(сертификат хуҗасы яки аның законлы вәкиле күрсәтелә)

______________________________________________________________
(документ исеме, номеры һәм сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________

2. Инвалид бала турында мәгълүмат ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,

______________________________________________________________
туган көне, ае, елы)

3. Сатып алынган товарның исеме, индивидуаль реабилитация яки инвалид баланы абилитацияләү программасының номерын һәм датасын күрсәтеп: ______________________________________________________________

4. Мөрәҗәгать итүченең элемтә телефоны һәм инвалид баланың яшәү урыны адресы:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү өчен гаиләгә килү датасы һәм вакыты турында мәгълүмат алуга риза:

әлеге адрес буенча язмача формада________________________________________

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча ________________________________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ________________________________________________

(«әйе» яки «юк» дип күрсәтергә)

«__» _________ 20__ ел. _________________ ____________________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

--------------------------------

* Товар инвалид балаларны җәмгыятькә социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү өчен билгеләнгән.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

кисем линиясе

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның булуын тикшерү актын бирү турындагы гариза 20___ елның __________ кабул ителде һәм № __ белән теркәлде.

_____________ ________________________________________________________________

(имза) (белгечнең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

___________ элемтә өчен тел.